Республика Татарстан
Старо-Имянское сельское поселение
Сармановского муниципального
района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының
Иске Имән авыл җирлеге

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**20.09.2019 ел** **№125**

**Референдум уткәру инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендаге 131-ФЗ номерлы 22, 56 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Иске Имән авыл җирлеге Уставының 11 ст., нигезендә Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ.:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уткәру инициативасы белән чыгарга:

"1 нче төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт утүче гражданнардан кала, Иске Имән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 2020 елда үзара салым акчасын 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

- Иске Имән торак пунктының Мулланур Вахитов, Каратал, Нәҗип Вахитов, Сарысаз-Ткермән торак пунктының Карл Маркс, Чапаев урамнарына вак таш җәю (таш ташу);
- Иске Имән, Сарысаз Тәкермән авылларында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
- Иске Имән, Сарысаз Тәкермән авылларында Сабантуй бәйрәмен уткәру өчен бүләкләр сатып алу;
- махсус техника Беларусь-МТЗ 320.4-Ч тоту (сатып алу ягулык-майлау материаллары);
- Иске Имән, Сарысаз Тәкермән авылларында урам утларын ремонтлау (лампаларны алыштыру) ;

ӘЙЕ ЮК"

2. Әлеге карар авыл җирлегенең мәгълумат стендларына һәм рәсми сайтына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Иске Имән авыл җирлеге рәисе Р.Ә.Исламова